# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**“Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 31 гыйнварында
кабул ителде

**1 статья**

“Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында” 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендәге “Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең” сүзләрен “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең” сүзләренә алмаштырырга;

2) преамбулада “Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең” сүзләрен “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең” сүзләренә алмаштырырга;

3) 1 статьяда “5.3 – 5.6” саннарын “5.6” санына алмаштырырга;

4) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ статья өстәргә:

“1[1] статья. **Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелә торган муниципаль берәмлекләрнең исемнәре**

Татарстан Республикасында түбәндәге муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелә:

Казан шәһәре, “Чаллы шәһәре”, Әгерҗе муниципаль районы, Азнакай муниципаль районы, Аксубай муниципаль районы, Актаныш муниципаль районы, Алексеевск муниципаль районы, Әлки муниципаль районы, Әлмәт муниципаль районы, Апас муниципаль районы, Арча муниципаль районы, Әтнә муниципаль районы, Баулы муниципаль районы, Балтач муниципаль районы, Бөгелмә муниципаль районы, Буа муниципаль районы, Югары Ослан муниципаль районы, Биектау муниципаль районы, Чүпрәле муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы, Зәй муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Кайбыч муниципаль районы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кукмара муниципаль районы, Лаеш муниципаль районы, Лениногорск муниципаль районы, Мамадыш муниципаль районы, Менделеевск муниципаль районы, Минзәлә муниципаль районы, Мөслим муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы, Яңа Чишмә муниципаль районы, Нурлат муниципаль районы, Питрәч муниципаль районы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Саба муниципаль районы, Сарман муниципаль районы, Спас муниципаль районы, Тәтеш муниципаль районы, Тукай муниципаль районы, Теләче муниципаль районы, Чирмешән муниципаль районы, Чистай муниципаль районы, Ютазы муниципаль районы.”;

5) 3 статьяда:

а) 1 өлештә “Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына” сүзләрен “муниципаль берәмлекләр бюджетларына” сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 һәм 3 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләрнең күләмен исәпләү әлеге Законга кушымта нигезендә Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен исәпләү методикасы нигезендә башкарыла.

3. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләме Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.”;

6) кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасында муниципаль
берәмлекләрнең җирле үзидарә
органнарына административ хокук
бозулар турында беркетмәләр төзүгә
вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген
билгеләү буенча Татарстан
Республикасының дәүләт
вәкаләтләрен бирү хакында”
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен исәпләү методикасы**

Әлеге Методика административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыруга муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен һәр муниципаль берәмлеккә карата исәпләү өчен каралган.

I-муниципаль берәмлеккә субвенцияләр күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$S_i = O_i / V \times R$,

монда:

$S_i$ – i-муниципаль берәмлеге өчен дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенция күләме;

$O_i$ – хезмәт хакына карата түләүләрне исәпкә алып, акчалата тулаем хезмәт хакын түләүгә чыгымнар (бер елга исәпләгәндә);

V – планлаштырыла торган елга производство календаренда билгеләнгән эш вакыты, сәгатьләрдә;

R – административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында норматив актны әзерләүгә вакыт нормасы (3 сәгать күләмендә билгеләнә).

Хезмәт өчен түләүгә чыгымнар түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$O_i = (Z_i + N_i) \times 12$,

монда:

$Z_i$ – муниципаль берәмлекнең хезмәт өчен түләүнең кайсы төркеменә каравын исәпкә алып, муниципаль район (шәһәр округы) башкарма комитетының (башкарма комитет аппаратының) идарәсе, бүлеге, секторы, башка структур бүлекчәсе баш белгече вазыйфасы дәрәҗәсендә билгеләнә торган айлык тулаем хезмәт хакы күләме;

$N_i$ – хисап чорында хезмәт хакына карата түләүләр.

Хезмәт хакына карата түләүләргә чыгымнарны исәпләп чыгару түбәндәге формула буенча башкарыла:

$N_i = Z_i \times F$,

монда F – хезмәт хакына карата түләүләр ставкасы.”.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. Әлеге Законның гамәлдә булуы 2013 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 4 феврале
№ 9-ТРЗ